ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**13.11.2019**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№2420**

2020 елга Зеленодольск муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларының норматив чыгымнарын раслау турында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273 номерлы Россия Федерациясе Законының 99 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 1 өлешенең 11 пункты, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Зеленодольск муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларын норматив финанслауны кертү турында» 2007 елның 21 декабрендәге 1879 номерлы карары нигезендә Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. 2020 елга Зеленодольск муниципаль районының гомуми белем бирү оешмалары һәм гомуми белем бирү интернат мәктәпләрендә тәрбияләнүчеләрне тотуга беркетелгән норматив чыгымнарны расларга.
2. 2019 елның 02 октябрендәге «2020 елга Татарстан Республикасында гомуми белем бирү оешмаларында һәм һөнәри белем бирү оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем, шулай ук өстәмә белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен финанс белән тәэмин итү нормативларын раслау турында» 76-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән расланган мәгариф оешмаларының норматив чыгымнары нигезендә «Зеленодольск муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы» МУ мәгариф оешмаларын финанслауны тәэмин итәргә;

әлеге карарның 1 пункты белән.

3. Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппаратының җәмәгатьчелек һәм ММЧ белән элемтә бүлеге башлыгына әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) Интернет челтәрендә урнаштырырга..

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2020 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла

5.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплыгымда калдырам.

Җитәкченең беренче урынбасары А.В. Старостин

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2019 нчы елның 13нче ноябрендәге
2420 нче номерлы карарына карата
1нче кушымта

**Зеленодольск муниципаль районының гомуми белем бирү оешмалары каршындагы интернатларда һәм гомуми белем бирү интернат-мәктәпләрендә тәрбияләнүчеләрне тотуга**
**НОРМАТИВ ЧЫГЫМНАР**

| Гомуми белем бирү оешмасының тип һәм төрләре | Территориаль дислокация | Елына бер тәрбияләнүчегә норматив чыгымнар, сумнарда |
|---|---|---|
| Гомуми белем бирү оешмасы каршындагы интернат | шәһәр җирлеге | 90980 |
| | авыл җирлеге | 92342 |
| Гомуми белем бирү интернат-мәктәбе | шәһәр җирлеге | 137238 |
| | авыл җирлеге | 141713 |